РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ | КАРАР

14 сентябрь 2022 | № 135

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган хезмәт хакы шартлары турында нигезләмәне раслау хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 2 августындагы 751 номерлы карары нигезендә «Бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган хезмәт хакы шартлары турында»гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 30.03.2018 елның 195 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында», Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының аерым оешмалары хезмәткәрләренә социаль гарантияләр тәэмин итү һәм аларның хезмәтенә түләүне тәртипкә салу максатларында, Әтнә район Советы КАРАР ИТТЕ:

1. "Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган хезмәт хакы шартлары турында"гы Нигезләмәне расларга (1нче кушымта).

2. Әтнә район Советының « Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган хезмәт хакы шартлары турында »гы 16.04.2018 ел, №102 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен Әтнә муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе Ф.И. Гыймадиевка йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Әтнә муниципаль районы башлыгы -**
**Әтнә район Советы рәисе** **Г. Г. Хәкимов**